**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

19.05.2016 Яр Чаллы № 1721

Файдаланылмый торган биотермик
чокырларны бетерү буенча комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 25 декабрендәге 74228-МР номерлы күрсәтмәсен файдаланылмый торган биотермик чокырларны бетерүгә кагылышлы өлешендә үтәү йөзеннән,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы территориясендә файдаланылмый торган биотермик чокырларны бетерү буенча комиссия төзергә.
2. Расларга:
- әлеге карарга 1 кушымта нигезендә комиссия составын;
- әлеге карарга 2 кушымта нигезендә комиссия турында нигезләмәне.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев